**Усманова Гөлнур Мөхәмәт кызы**
Әлмәт районы
№9 "Садко" балалар бакчасы

# "ХИКМӘТЛЕ ДӘ, СЕРЛЕ ДӘ ТЕАТР"

## /МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕНДӘ АЧЫК ДӘРЕС/

***Максат:*** *Балаларның театр тарихы һәм шулай ук халкыбыз театры турында белемнәрен үстерү. Уйлау, фикерләү, үзара аралашу сәләтләрен камилләштерү. Иҗади фикерләү сәләтләрен активлаштыру. Театр турында белемнәрен системалаштыру. Балаларның рухи дөньяларын баету, аларны әхләкый һәм эстетик тәрбияләү. Халкыбыз сәнгатенә ихтирам, күңел нәфислеге тәрбияләү.*

***Җиһазлау:*** *Әкияткә кирәкле костюмбитлекләр, магнитофон язмасы, театр афишасы, китаплар күргәзмәсе, әкиятләр күргәзмәсе, «Театр тәзибез», «Һөнәрләр» уеннары, театр күренеше слайды.*

*Алдан эшләнгән эшләр: Театр турында видеослайдлар карау, видео һәм аудио кассеталардан театр турында мәгълүматлар белән танышу, төрле жанрдагы театрлар карау, әкиятләрне рольләргә бүлеп өйрәнү, әти-әниләр белән табигать материалларыннан "Сихри дөнья, серле дөнья" исеме астында конкурс уздыру, "Үз әкиятем булсын әле" исеме астында күргәзмә оештыру, сюжетлырольле уеннар: "Театр", "Режиссер".*

**Дәреснең барышы:**

Балалар "Туган телем" *(М.Минһаҗев)* көенә залга керәләр, ярымай булып басалар.

- Хәерле көн, балалар! Бүген 27 нче март-театр көне, димәк бүген театр бәйрәме. Менә бу афишага игътибар итегез әле, бу битлекләр сезгә танышмы?

- Болар трагик һәм комик битлекләр.

- Алар нәрсәне аңлата соң?

- Бу битлекләр театрның символы.

- Бик дөрес, балалар, бу битлекләр театрда кайгылы да, көлкеле дә хәлләр турында уйналынганын аңлатып торалар. Театр - ул бик борынгы сәнгать һәм ул үзенең серлелеге белән кешеләрне үзенә тартып торган. Театр, театр дибез, ә беренче театрны кемнәр уйлап тапкан соң?

Беренче театрны греклар уйный башлаганнар.

*/Тын көй яңгырый, театр слайды күрсәтелә./*

- Дөньяда Греция дигән ил бар, анда грек халкы яши. Менә алар бик күп еллар элек үзләренең геройларының, аллаларының батырлыкларын спектакль итеп уйнаганнар һәм бу театр уйнала торган бина вакытлар үтү белән театр бинасы дип атала башлаган. Үз театрларында алар көлкеле дә, кызыклы да, ә кайчагында бик күңелсез хәлләрне дә уйнаганнар һәм халыкка яхшыны яманнан, дөреслекне ялганнан аерырга дөрес юл табарга өйрәткәннәр.

- Балалар, ә сез беләсезме, татар театры ничек, кайдан килеп чыккан? Тыңлагыз. Сезгә яхшы таныш бәйрәмнәр "Сабантуй", "Сөмбелә", "Карга боткасын" бәйрәмнәрендә бәләкәй генә рольләр уйналып шулай башланган.

Театр бит әле ул, балалар, яңа сүзләр дөньясы да көнкүрештә кулланылмый торган сүзләрне без театрда очратабыз. Балалар, сезнең барыгызның да театрга барганы бар, әйдәгез, бергәләп менә шул мольбертта театр макетын тәзибез.

*/Балалар мольбертта әлешләрдән театрның эчке күренешен тәзиләр./*

Бу тамашачылар залы - рәтләр, урындыклар, портьер дип атала. Театрда тагын балкон да була.

Артистлар уйный торган җир – сәхнә.

Пәрдә – сәхнәне спектакль башланганчы каплап, яшереп тора.

Сәхнәнең алды – анда төрле лампочкалар яна, сәхнәне яктырта.

Сәхнә арты – анда артистлар үз чыгышларын көтеп торалар.

- Менә безнең театр бинабыз әзер дә. Булдырдыгыз, балалар, мондый белемнәрегез белән сез театрда адашмыйча йөри алачаксыз.

- Ә менә бу сәхнәдә әкият, спектакльләрне куяр өчен бик күп төрле һөнәр кешеләре эшли, әйдәгез, үзебезнең "театрыбызны" шул һөнәр кешеләре белән тулыландырып бетерик.

*/ Театр макетына һөнәр кешеләренең рәсемнәрен урнаштыралар./*

Драматург – спектакльне, пьесаны яза.

- Балалар, татар халкының танылган драматургы бар, аның исемен Казан драмтеатры йөртә *(Казан драмтеатрының рәсеме күрсәтелә)*, кем ул, балалар?

- Драматург Галиәскәр Камал.

- Әйе, балалар, ул безнең бөек шәхесләребезнең берсе. Театрда эшләүче тагын нинди һөнәр кешеләрен беләсез?

Декоратор – ул сәхнәне бизи.

Музыкант – спектакльгә көй яза.

Режиссер – спектакльне куйдыра.

Ут көйләүче – дөрес итеп сәхнәгә ут төшерә.

Артистлар - әкиятне уйнаучылар.

Билет сатучы – театрга билет сата.

- Булдырдыгыз. Сез театр турында болай күп белгәч әкиятне рольләргә бүлешеп үзегез дә уйный аласыз. Театрлар күп төрле, ә сез нинди театр жанрларын беләсез?

Опера – монда артистлар җырлыйлар гына.

Балет – бу жанрда сөйләшмиләр дә, җырламыйлар да, ә әкиятне биеп кенә башкаралар.

Курчак театрында артист апалар, абыйлар курчакларны хәрәкәтләндерәләр, алар өчен сөйлиләр дә, җырлыйлар да.

Пантомимо – артистлар бит, кул, аяк хәрәкәте белән уйныйлар.

Бу жанрны без дәресләрдә дә кулланабыз, әйдәгез берәр сюжет күрсәтик.

*/1-2 бала пантомимо жанрына сюжетлар күрсәтәләр.Бала елый, чәч үрә, озынборын тешли, урамда салкын./*

- Булдырдыгыз, рәхмәт.Тагын нинди театр жанрын беләсез? Ул безнең бик яраткан һәм бик таныш жанр.

Драмтеатр – монда артистлар бииләр дә, җырлыйлар да, сөйләшәләр дә.

- Бик дөрес.Ә безнең Әлмәт драмтеатрының бинасы кайда урнашкан?

Әлмәт драмтеатр бинасы Ленин мәйданында урнашкан.

- Без күп тапкырлар театр бинасын күргәнебез бар. Анда күпләрегезнең театр караганыгыз да бар.Театр ул тылсым, әкият. Ә әкият нәрсә ул, балалар?

Тылсым.
Серле дөнья.
Сихри дөнья.
Шатлык, матурлык.
Хыял.
Хикмәт.

- Әйе, балалар, әкият искиткеч дөнья. Анда җәнлекләр дә, таулар да, диңгезләр дә сөйләшә беләләр. Әкиятләр безне нәрсәгә өйрәтә соң?

Дус булырга.
Олыларны олыларга.
Табигатьне яратырга.
Көчле булырга.
Урлашмаска, алдамаска.
Үз-үзеңә ышанырга.
Кыюлыкка.
Нәниләргә булышырга.
Үз телеңдә матур итеп сөйләшергә.
Үз илеңне яратырга.

- Бик дөрес, балалар, әкиятләр начарлыкның зур күңелсезлеккә китергәнен аңлата, ул фәкать яхшылыкка гына өйрәтә. Әйдәгез, без дә үзебезне театрда дип хис итик, артистлар булыйк әле.

*/ “Дуслар җыелган җирдә” әкияте куела./*

Өй эче. Ана бала тирбәтә һәм җырлый.

Әлли- бәлли итәр бу
Мәдрәсәгә китәр бу
Тырышып сабак укыгач
Галим булып китәр бу
Әлли-бәлли бәү итәр.

*/ Урамнан сызгыру тавышы ишетелә. Әнисе тәрәзәдән карый һәм улына эндәшә./*

Гали, улым, сиңа килделәр бугай.

*/ Гали икенче бүлмәдән чыга./*

Әни, кара әле син бу Акбайны. Һич тыңламый, һич аңламый.

Әйдәле, Акбай, өйрән син арт аягың белән тор.

Аума, аума, туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр.

Акбай: Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә.

Мин туганга тик ике айлап булыр, я өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә.

Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

Гали: Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул.

Картаеп каткач буыннар эш белү уңайсыз ул.

Әйдә, әнә безне чакыра килгәннәр, бергәләп урамда йөреп керик. */китәләр/.*

*/Урман. Шүрәле үзенең биләмәләрен карап йөри, кошлар сайравы ишетелә./*

*Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын. Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңлармын.*

*/Сәхнәнең икенче ягынан карана-карана, калтырана-калтырана Су анасы чыга. Икесе ике яктан килеп Шүрәле белән бәрелешәләр./*

**Шүрәле:** Бу тагын кем? Әй, син кем?Нигә минем урманымда рөхсәтсез йөрисең?

**Су анасы:** Ой-ой-ой. Зинһар кычкырма шулай. Күрмисеңме, ничек калтыранам, җитмәсә бакаларымны, балыкларымны да бик сагындым. Су анасы мин. Су анасы.

**Шүрәле:** Су анасы булгач, бар үзеңнең суыңа элдерт. Минем урманымда рөхсәтсез йөрмә. Бу сиңа турагенство түгел.

**Су анасы:** Әй, синең урманыңда йөрергә бик рехәт дип белдеңме әллә? Хәлемнән килсә суымнан чыкмас та идем. Ләкин җөй көне ялгышып алтын тарагымны басмада калдырганмын, бер авыл малае тарагымны урлап качты. Алтын тарактан башка нинди су анасы инде мин? Менә мин шул малайны, шул авылны эзлим. Булыш әле миңа, урман хуҗасы.

**Шүрәле:** Һай, Су анасы, аңлыйм мин синең хәлеңне. Беләм мин ул малайны, аның абыйсы Былтыр, бармакларымны шундый итеп кыстырды. Әле дә менә авыртып тора, өф-өф. */бармакларына өрә/*

**Су анасы:** Тизрәк әйт, кайда ул авыл?

Шүрәле: Авылмы? Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр.

Җырлаганда көй өчен тавыклары җырлай диләр...

**Су анасы:** Соң әйдә, киттек тизрәк шул Кырлайга!

**Шүрәле:** Э-э-э, ашыкма, алар авылда түгел шул. “Пар ат”ка утырып Казанга киттеләр.Үзем күрдем.

**Су анасы:** Һай кайгы минем башкайларыма, һай балыкларым, һай бакаларым.

**Шүрәле:**Я, ярар, алай бетеренмә әле, әлегә миндә кунак булырсың.Минем урманымның нинди матур икәнен белмисең бит әле син. Бу сиңа су төбе түгел.

*/Сәхнәнең икенче ягыннан Кәҗә белән Сарык киләләр/*

**Кәҗә:** Исән-ме-сез, ур-ман ияләре!

**Сарык:** Урманыгызда төн кунарга рөхсәтме?

**Шүрәле:** Кемнәр сез?Минем урманымда мондый җәнлекләр юк!

**Кәҗә:** Без, Сарык дус белән авылда бер ярлы гаиләдә яшәдек, ашатырга ризык беткәч, чыгарып җибәрделәр.

**Сарык:** Нишли инде мескен Кәҗә белән Сарык? Булмый хуҗа кушканга каршы барып.

Икебезгә зур гына бер капчык тегеп,
Киттек менә кырга таба сәфәр чыгып.

**Шүрәле:** Ярар, калыгыз, әнә теге якты аланга барыгыз.

*/Кәҗә белән Сарык китәләр, Шүрәле белән Су анасы агач артына качалар. Сәхнәгә Күбәләк белән Кыз йөгереп керәләр/*

**Күбәләк:** Нигә дип һаман минем артымнан йөгерәсең? Әллә мине чәчәк дип белдеңме? Миңа тияргә ярамаганын да белмисең ахыры. Минем гомерем бик кыска бары бер көн генә.

**Кыз:** Әйт әле, Күбәләк, сөйләшик бергәләп. Бу кадәр күп очып, арымыйсың син ничек?

**Күбәләк:** Шундый матур кояш балкыганда, матур чәчәкләр тирә якта үсеп утырганда ничек арыйм инде мин, миңа бик күңелле.

**Кыз:** Тукта, тукта инде күбәләккәй. Кайда очтың, сөйләшик инде бераз.

*/чыгып китәләр.Шүрәле белән Су анасы чыгалар/*

**Шүрәле:** Бу Кыз нәрсә дип адашып урманда күбәләк куып йөри инде тагын.

**Су анасы:** Әй, аңламассың аларны.

*/Гали керә, кемнедер эзли/*

**Су анасы:** Бу бит минем тарагымны урлаган малай. Һай кирәген бирәм хәзер. Ах, оятсыз малай, китер хәзер үк минем алтын тарагымны.

**Шүрәле:** Кеше әйберен сорамый алырга ярамаганын бакчада өйрәтмәделәр мени?

**Гали:** Беләм мин барын да, Шүрәле белән Су анасы. Алтын тарагыңны да бирәм, тик бер шартым бар.

**Су анасы:** Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?

Сөйлә тизрәк, нәрсә кушсаң да күнәм.

**Шүрәле:** Син авызыңны чамалап ач, яме. Бу кешеләрне белмәссең. Мин шулай Былтырның тозагына эләктем инде.

**Гали:** Риза булсагыз, тыңлагыз! “Шүрәле” һәм “Су анасы” әкиятләрен нинди жанрларда уйныйлар?

**Су анасы:** Нәрсә, нәрсә, жанр диме?

**Шүрәле:** Соң, без аны кайдан белик, без бит бакчага йөрмәдек, мәктәптә дә укымадык.

**Гали:** Соң, боларны бит телевизордан да күрсәтәләр.Үзегез белмәсәгез, әнә, бакчага йөри торган кызлардан, малайлардан сорагыз.

**Шүрәле:** Карале, Су анасы, синең күлеңдә телевизор бармы соң? Минем урманымда юк.

**Су анасы:** Юк шул. Кызлар, малайлар, булышыгыз инде безгә бу сорауга җавап табарга.

**Балалар:** “Шүрәле”, “Су анасы” әкиятләре курчак театрында, балет һәм драмтеатрда уйнала.

**Су анасы:** Рәхмәт сезгә, кызлар, малайлар.

**Гали:** Мә, Су анасы, тарагыңны, миңа өйгә кайтырга кирәк, әнием көтәдер. */китә/*

**Шүрәле:** Без бигрәк наданнар икән без, болай булгач, мәктәпкә дә йөрми булмас.

**Су анасы:** Шулай шул, Шүрәле. Уку - белем чишмәсе, дип юкка гына әйтмиләр.

*/Театр артистлары бергәләп чыгып саубуллашалар/*

Шуның белән безнең театрга багышланган дәресебез тамам. Барыгызга да зур рәхмәт. Бүгенге дәрестә сезнең театр турында күп белүегез бик шатландырды. Мин сезгә киләчәктә дә бу белемнәрегезнең үстәлеп, баеп торуын телим. Сау булыгыз!

“Ачык дәрес”
**нәшрият йорты**
Гамәлгә куючы һәм баш редактор
**ЛАТЫЙПОВА
Альбина Шамилевна**

*Март, 2011.*
Хатлар өчен адрес: 420102, Казан - 102, а/я 27. Белешмәләр өчен телефон: 89372834757. Тел./факс (843) 562-27-74. e-mail: achik-dares@yandex.ru
Газета сатуга чыгарылмый.
*Тираж 6900 экз.*

Басарга кул кую вакыты: һәр айның 15 числосы.

*«Ачык дәрес. Мәктәп» газетасына Россиянең барлык өлкәләрендә дә теләсә кайсы айдан язылырга мөмкин. Язылу индексы - 16853*

Редакция сценарийларны рецензияләми һәм кире кайтармый. Материаллар бары тик почта һәм электрон почта аша гына кабул ителә. “Газетное издательство” басмаханәсендә басылды. (Казан, Восстание ур., 100). Авторларның язмалары өчен редакция җавап бирми. Юр.адрес: 420102, Казан, Ягодинская ур. 35/27б. (Оешмаларның рәсми хатлары өчен генә). “Ачык дәрес. Мәктәп” газетасы Роскомнадзор Федераль хезмәтендә ПИ № ФС77-37050 номеры белән 2009 елның 31 июлендә теркәлде.

Материаллар өчен тиешле гонорар ярдәмгә мохтаҗ балаларга күчерелә.